КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 54

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче, 2022 ел, 25 июль, 716 нчы, 2022 ел, 30 ноябрь, 1270 нче, 2023 ел, 21 март, 305 нче, 2023 ел, 2 июнь, 680 нче, 2024 ел, 29 март, 202 нче, 2024 ел, 30 май, 377 нче, 2024 ел, 4 декабрь, 1094 нче, 2024 ел, 21 декабрь, 1181 нче, 2025 ел, 16 апрель, 235 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктның беренче абзацында «, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән» сүзләрен «өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктта «Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган «Тәрбия буенча ярдәмче» хемәте» сүзләрен «өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктның икенче абзацында «15» саннарын «31» саннарына алмаштырырга;

4.4 пунктның 2 пунктчасында «Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган «Тәрбия буенча ярдәмче» хемәте» сүзләрен «исемлеге сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр» сүзләренә алмаштырырга;

4.6 пунктның 2 пунктчасындагы бишенче абзацында «Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган «Тәрбия буенча ярдәмче» хемәте» сүзләрен «өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина оешмасы бәяләмәсе;»;

5.3 пунктның икенче абзацында «15» саннарын «31» саннарына алмаштырырга;

5.11 пунктның 1 пунктчасында «, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында китерелгән» сүзләрен «өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә» сүзләренә алмаштырырга;

5.13 пунктта «15» саннарын «31» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 - 2027 елларда «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә субсидия бирү тәртибендә:

5.6 пунктның беренче абзацында «хисап чорыннан соң килүче» сүзләреннән соң «(хисап чорыннан соң килүче елның гыйнварында - 15 числога кадәр)» сүзләрен өстәргә;

5.11 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Агымдагы финанс елының 31 декабренә торышы буенча файдаланылмаган субсидия акчалары субсидия алучылар тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.»;

6.1 пунктның беренче абзацында «15» саннарын «31» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин